**Укытучыларыбызны хөрмәтлибез.**

2нче гимназиянең “Ак җилкәннәр” тимурчылар  отряды  шәһәрдә һәм мәктәптә бик күп изге  эшләр башкара. Әле күптән түгел безнең башлангыч белән  гимназиядә иртәнге зарядка үткәрелде. Барлык гимназия укучылары анда актив катнашты. Класс советыәгъзалары яңа башлангычны сыйныф-ларда дәвам итәрләр дип ышанабыз.

Бу көннәрдә без,тимурчылар,”Укытучыны котла!” акциясендә  катнашабыз.

Дәрестән соңбез ГЭС бистәсенә җыелдык. Максатыбыз -  укучыларының рәхмәт сүзләрен яраткан укытучыларына җиткерү.Урамнан үтүчеләр тимур-чылар әзерләгән котлау открыткаларына күңел түрләреннән чыккан рәхмәт сүзләрен яздылар.Алар арасында  мәктәпне күптән тәмамлаган өлкәннәр дә, яңа гына уку йортларын  бетергән студентлар да бар. Яшьләр арасында сөекле мөгаллимнәрен бәйрәм белән котлаучы яшьләр күп булу безне сөендерде. Еллар үтеп олыгая барган саен элекке укучыларның укы-тучыларын   онытмавы, киресенчә, аларга хөрмәт һәм рәхмәтләре арта бару һәммәбезне шатландырды. Ә хәзер бәйрәм котлауларын хуҗаларына илтеп җиткерәсе генә калды.

Укытучылар көне уңаеннан бу көннәрдә гимназиядә зур әзерлек бара. Без, тимурчылар, сөекле укытучыларыбызга күп төрле чаралар әзерлибез. Иртән мөгаллимнәребезне музыка астында йолдызлы юллы “тере коридор” аша каршы алырга уйлыйбыз.Флешмоб та әзерләдек.Укытучыларыбызга телевизор аша видиокотлау  тапшырачакбыз.  Алар өчен эти- әниләр белән берлектә концерт-тамаша  оештырабыз. Бәйрәм көнне укытучыларыбыз өченбәйрәм кафесы эшләячәк.Рәхәтләнеп ял итсеннәр.Бәйрәм көнне Үзидарә кө-не оештырып,администрация һәм педагогларны алыштырырга уйлый-быз.Укытучыларыбыз дәресләр үткәрергә һәммәбезне алдан әзерләде. Сынатмабыз дип уйлыйбыз.

Серебезнең барсын да ачып бетермик әле...

Укытучыларыбызны якынлашып килүче бәйрәм белән котлыйбыз.Сау – сәламәт булыгыз, иҗади уңышлар Сезгә!

“Ак җилкәннәр” тимурчылар отряды әгъзалары  исеменнән Филимонова Диана.


0 руб
0 руб


КРЕПЕЖ
ИНСТРУМЕНТЫ
ТАТМЕТИЗ


КРЕПЕЖ
ТАТМЕТИЗ
ИНСТРУМЕНТЫ


0 руб
0 руб
ЛИМИТ
Билайн


КРЕПЕЖ
ТАТМЕТИЗ
ИНСТРУМЕНТЫ
МЕБЕЛЬ










ARIZONA










**“Йолдызлы юлдан рәхим ит, укытучы-йолдызыбыз!”- Ал җилкәнлеләр укытучыларны котлау-хөрмәтләүнең төрле форматаларын уңышлы кулланды: видио-котлау, бәйрәм почтасы, флэшмоб, бәйрәм  кафесы оештыру, концерты,”Оскар” премиясе номинацияләрен тапшыру , һ.б.**






**Класс ишекләрендәге йөрәкләрдә һәр укытучыга безнең рәхмәт сүзләреязылган.**




**“Дәрестә яңа технологияләрне отышлы кулланабыз!”-**

**тимурчылар дәрес бирә.**




**Укытучыларыбызга охшарга тырышабыз. Дәресләребез яхшы үтә.**









**“Яхшы әзерләнсәң, дәресең дә нәтиҗәле уза,” дип сөенә тимурчы Диана Филимонова**




Вас!






**“Быел мәктәптә соңгы елыбыз!”**




**Класс советлары да безнең башлангычка актив кушылды.**




**“ Бәйрәм кафесында укытучыларыбызны тәмле ризыклар белән сыйладык.”**





**“Мин бүген укытучы ролендә”.**




Алсу Хамитовна
Бәйрәм белән
Алсу Хамитовна!
С Днём Учителя!



**Әти-әниләр белән бергә  мөгаллимнәребезгә бәйрәм концерты оештырдык.**



**“Укытучыңны котла!” акциясе дәвам итә.**



**Каян гына килми котлаулар!**



**Шатлык өләшүче  “Ал җилкән” отряды тимурчылары**



**“Конверт эчендә котлау бар!”**






**“5” леләребез укытучыларыбызга бәйрәм бүләгебез булсын!”**



**Мөгаллимнәребезне шәһәр хакиме  урынбасары котлый.**



**“Чираттагы “Оскар” премиясе иясен сәхнәгә тапшырабыз...”**



**“Бәйрәмдә һәр укытучы халыкара “Оскар” премиясенең бер номинациясенә  лаек булды”**







**“Әти-әниләр комитеты белән бергә чыгыш ясыйбыз.”**









**“Бездә  яхшы  укучылар,  Иң гадел мөгаллимнәр”.**